ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
КАРАР

№ 5 2021 ел, 8 ноябрь

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Иске Мукшы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Иске Мукшы авылы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 19 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Иске Мукшы авылы, Яшел урамы, 1 йорт адресы буенча, Иске Мукшы авыл клубы бинасында билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

   «2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Иске Мукшы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- Иске Мукшы авылы торак пункты чикләрендә вак таш түшәмәле юл полотносы урнаштыру (грунтлау, грейдлау, вак таш түшәү, ком сибү, килешү буенча эшләр өчен түләү).

- Иске Мукшы авылы торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, агынты суларны чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- Иске Мукшы авылында тирән насос сатып алу һәм алыштыру, суүткәргечне ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру

- Иске Мукшы авылы территориясендә үсемлекләрне чабу(килешү буенча эш өчен түләү).

Җирлек халкының ялын оештыру өчен шартлар тудыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре күрсәтү

- Иске Мукшы авыл клубы өчен ишек алу һәм алыштыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина